ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.12.2022**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 3593**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының.2021 елның 22 октябрендәге 2636 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 26 маендагы 489 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 20 июнендәге 587 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2021 елның 22 октябрендәге 2636 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 ноябрендәге 3024 номерлы,2022 елның 13 гыйнварындагы 24 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта нигезендә түбәндәге үзгәрешләр кертергә.
2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 елның
28 декабрендәге 3593 карарына
кушымта

1.1. IV бүлектә:

1 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 87 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "87. | Су асты спорты | 1,50 | 2,80 | 3,70 | 6,70 | 6,70 | 8,90 | 8,90 | 10,00 | 17,0 | 23,0 | 35,0"; |

2 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 87 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "87. | Су асты спорты | 4 | 6 | 8 | 12 | 12 | 16 | 16 | 18 | 24 | 24 | 32"; |

3 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 87 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "87. | Су асты спорты | 15 | 12 | 12 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 4 | 4 | 2"; |

1.2. VI бүлекнең 7 пунктындагы 7.3 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге 2245-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган, 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә спорт резервын әзерләү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын үтәгәндә спорт резервы әзерләүче оешмалар хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә һәм икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш һәм төп вазыйфа буенча, акча булган очракта, бер тапкыр түләнә торган түләү башкарыла.

Түләүнең тәртибе, шартлары һәм билгеле бер күләме күрсәтелгән максатларда спорт резервын әзерләүче оешмаларның локаль норматив актлары белән билгеләнә.";

1.3. VIII бүлектә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр эшчәнлекнең эффективлык критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, спорт резервын әзерләүче оешманы гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.";

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесе урынбасарына, баш бухгалтерына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр аларның эшчәнлегенең эффективлык критерийлары

нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, бер ел эшләү йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен кертелергә мөмкин. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең иң чик күләме спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә башкарган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүнең 70 процентына кадәр күләмдә билгеләнә.";

9 пунктның беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесенә тренерлар тарафыннан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм ярышларда спортчылар һәм спортчы-инструкторлар алган нәтиҗәләр өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күрсәтелгән оешманы гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Спорт резервын әзерләүче оешма җитәкчесе урынбасарына, баш бухгалтерга тренерлар тарафыннан югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен һәм ярышларда спортчылар һәм спортчы-инструкторлар алган нәтиҗәләр өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күрсәтелгән оешма җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.